ГЛАВА
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.12.2025 Баулы шәһәре №212

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Шалты авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проекты буенча иҗтимагый фикер алышулар билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Советының 2018 елның 3 июлендәге 160 номерлы карары, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Уставының 17 статьясы белән расланган, Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә ачык тыңлауларны оештыру (җәмәгать фикер алышулары) һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә

КАРАР ИТӘМ:

1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Шалты авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проекты (алга таба - Проект) буенча ачык тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.

2. Проект буенча иҗтимагый фикер алышулар инициаторы – Баулы муниципаль районы Башлыгы.

3. Иҗтимагый фикер алышуларны уздыруны 2025 елның 17 декабреннән 2026 елның 17 гыйнварына кадәр билгеләргә.

4. Иҗтимагый фикер алышуларда каралырга тиешле проект экспозициясен 2025 елның 17 декабрендә ачарга:

4.1. Экспозицияне уздыру урыны:

- Татарстан Республикасы Баулы районы Шалты авыл җирлеге башкарма комитеты

бинасында: Татарстан Республикасы, Баулы районы, Шалты авылы, Совет ур., 56 й. адресы буенча;

- «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә www.bavly.tatarstan.ru Баулы муниципаль районы сайтында.

4.2. Экспозицияне карау режимы:

-Татарстан Республикасы Баулы районы Шалты авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында: Татарстан Республикасы, Баулы районы, Шалты авылы, Совет ур., 56 й. адресы буенча;

Эш көннәрендә Мәскәү вакыты белән 8.30 дан 11.30 сәгатькә кадәр, 13.30 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр.

5. Җәмәгать фикер алышуларында катнашучылар 2025 елның 17 декабреннән 2026 елның 17 гыйнварына кадәр эш көннәрендә, Мәскәү вакыты белән 8.30 дан 11.30 га кадәр, 13.30 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр җәмәгать тыңлауларында каралырга тиешле проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертергә хокуклы:

-язмача рәвештә җәмәгать тыңлауларын оештыручыга: Баулы шәһәре, Куйбышев урамы, 20 йорт, 101 каб. адресы буенча;

- по электронной почте Bauly.arch@mail.ru.

6. Иҗтимагый фикер алышуларны оештыручы итеп, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитетын (алга таба - җәмәгать фикер алышуларын оештыручы) билгеләргә.

7.Иҗтимагый фикер алышуларны оештыручыга:

7.1. Проектны карау буенча иҗтимагый фикер алышулар уздыруны тәэмин итәргә;

7.2. Проект буенча иҗтимагый фикер алышулар башлану турында Татарстан Республикасы Баулы муниципаль берәмлеге Шалты авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында мәгълүмат стендында Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге сайтында (www.Bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга;

Экспозицияләрне Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының Шалты авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында 2025 елның 17 декабреннән 2026 елның 17 гыйнварына кадәр эш көннәрендә, Мәскәү вакыты белән 8.30 дан 11.30 сәгатькә кадәр, 13.30 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Баулы муниципаль районы сайтында www.bavly.tatarstan.ru оештырырга;

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы башлыгы И.И. Гозәеров